ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2020 № 266

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең штат саны турында» Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 октябрендәге 458 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы үтенечнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән 2014 елның 10 декабрендәге 5899 номерлы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиягә өстәмә белем алуга кушымталары нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең штат саны турында» 2018 елның 29 октябрендәге 458 номерлы карарындагы 2 нче кушымтага (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең штат саны) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «1 нче гимназия» 1 нче пунктына 2020 елның 1 ноябреннән «0,5» штат берәмлекләре саны белән «Пешекче» вазифасын өстәргә;

- «2 номерлы мәктәп» 2 нче пунктына 2020 елның 1 ноябреннән «0,5» штат берәмлекләре саны белән «Пешекче» вазифасын өстәргә;

- «3 номерлы мәктәп» 3 нче пунктына «Тәрбияче» штат берәмлекләреннән «2,4» штат берәмлекләре саны белән «Өстәмә белем педагогы» вазифасын, 2020 елның 1 ноябреннән «0,5» штат берәмлекләре саны белән «Пешекче» вазифасын өстәргә;

- «4 номерлы мәктәп» 4 нче пунктына 2020 елның 1 ноябреннән «0,5» штат берәмлекләре саны белән «Пешекче» вазифасын өстәргә;

- «Исәнбай урта мәктәбе» 7 пунктында «2» штат берәмлекләре санында «Каравылчы» вазифасын төшереп калдырырга;

- «С-Омга лицее» 13 нче пунктына «Үсеш ноктасы» үзәге ачылу сәбәпле 2020 елның 1 ноябреннән «0,5» штатлы берәмлекләре санында «Өстәмә белем бирү педагогы» вазифасы белән тулыландырырга;

- «Тирсә мәктәбе» 14 нче пунктында «0,25» штат берәмлекләре санында «Тәрбияче» вазифасын, «0,25» штат берәмлекләре санында «Кече тәрбияче» вазифасын төшереп калдырырга;

- «Шаршада мәктәбе» 24 нче пунктына «Тәрбияче» штат берәмлекләреннән «0,11» штат берәмлекләре санында «Өстәмә белем бирү педагогы» вазыйфасын өстәргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына, әлеге карар нигезендә, оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**